**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Рус Богдашкиносы авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«16» октябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлеге Рус Богдашкиносы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкиносы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалид булганнардан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгәгә юнәлтергә:

   - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

   - су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

   - урамнарны яктырту җайланмасы.

Халык җыенында рәислек итүче: А. Л. Михайлова

Богдашкино авыл җирлеге башлыгы А.Л. Михайлова